ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**02.08.2024**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 2193**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 11 октябрендәге 2489 номерлы карары белән расланган, спорт разряды бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Спорт министрлыгының «Бердәм бөтенроссия спорт классификациясе турында нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 19 декабрендәге 1255 номерлы Россия Федерациясе Спорт министрлыгы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 11 октябрендәге 2489 номерлы карары белән расланган, спорт разряды бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба - Административ регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Административ регламентның 2.4.1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1 Спорт разрядын бирү өчен документларны карау срогы, аларны теркәгән көннән алып, 16 эш көне тәшкил итә»;

1.2. Административ регламентның 2.5.1 пунктындагы 2 пунктчаны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Документлар электрон формада тапшырылганда нотариус ЭП кул куйган нотариаль таныкланган тәрҗемә бирелә»;

1.3. Административ регламентның 2.5.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле «з», «и» пунктчалары белән тулыландырырга:

«з) региональ спорт федерациясенең дәүләт аккредитациясенең гамәлдә булуын туктатып тору турында башкарма хакимият органы документының күчермәсе (региональ спорт федерациясенең дәүләт аккредитациясенең гамәлдә булуын туктатып тору очрагында);

и) спорт разряды бирү (раслау) турында документ күчермәсе яисә өземтәсе».

2. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин